**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәр муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр**
**башкарма комитеты**
**422000, Арча ш., Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-15-25, 3-12-35**

**Муниципальное образование**
**город Арск**
**Арского муниципального района**
**Республики Татарстан**
**исполнительный комитет**
**города Арск**
**422000, г. Арск, площадь Советская , 27**
**тел. 3-15-25, 3-12-35**

# КАРАР

**« 09 » декабрь 2014 ел** **№ 187**

**Сатып алу юлы белән милекчедән жир кишәрлегенә һәм торакка хокукның өлешен муниципаль милеккә тартып алу**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 статьясы, Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясындагы 1-3, 10, 11 пунктлары, "Авария хәлендә дип танылган һәм сүтелергә тиешле торак йортлардан күчерелергә тиешле торак йортлар һәм гражданнар исемлеген раслау турында" Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2009 елның 29 декабрендәге 1199 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2013 елның 11 сентябрендәге карары белән расланган 2013-2015 елларга Арча муниципаль районының авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программага таянып (Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 7 апрелендәге 329 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), Арча муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Сатып алу юлы белән билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә дип танылган Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, М.Җәлил урамы, 9 йорт, 4 фатир адресы буенча урнашкан 16:09:010109:87:3:6 кадастр номерлы 61,9 кв.м. торакны (фатирны) (16:09:010109:87 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан) милекчедән муниципаль милеккә алырга.

2. Милекчеләргә муниципаль ихтыяҗлар өчен күрсәтелгән җир кишәрлеген һәм торак урынын алу турында хәбәр итәргә.

3. Милекчегә торак бинаның сатып алу бәясен 682 261 (алты йөз сиксән ике мең ике йөз алтмыш бер сум) 80 тиен тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән килешүләрне теркәүне гамәлгә ашыручы органда теркәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тору Арча шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р. Р.Шәмсетдиновка йөкләргә.

Арча шәһәре башкарма
комитеты җитәкчесе — Р. Р. Исмәгыйлев